Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет майданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

# КАРАР

« 28 » декабрь 2016 ел № 8

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районын Арча шәһәре муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Арча шәһәре Советының 07.07.2009 №426 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, максатларда ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында дәүләт хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча комиссия утырышы булды, шәһәр җирлеге торак пунктларында яшәүчеләрне Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышуда катнашу өчен карар бирәм:

1.28.01.2017 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 16 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт.

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар язмача 16 сәгатькә кадәр эш вакытында 27.01.2017 елда 8.00 дән 12.00 гә кадәр һәм

13.00 дән 17.00 гә кадәр ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресына җибәрелә дип билгеләргә, тел. 8(84366) 3-12-35.

4.Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

5.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында Арча шәһәре Советының әлеге карарын һәм карар проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча хәбәрләре газетасында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Касыймовка йөкләргә.

Арча шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча муниципаль районы
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Башлыгы карарына кушымта

28.12.2016 № 8

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты турында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы**

Эшче төркем рәисе:
Касыймов Р. Ф. - Арча шәһәре Башкарма комитет җитәкчесе
Эшче төркем секретаре:
Мамаделеева Р. Р.- «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары;
Эшче төркем әгъзалары:
Әмиров А.Г. - 4нче Арча сайлау округы буенча депутат;
Ильина Л. Ю. - 12 нче Арча сайлау округы буенча депутат;
Хәкимов И.Ү. - 14 нче Арча сайлау округы буенча депутат.